КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 27 апрель г.Казань № 300

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләвен арттыру турында» 2014 ел, 18 октябрь, 768 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләвен арттыру турында» 2014 ел, 18 октябрь, 768 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 21 октябрь, 791 нче, 2017 ел, 15 декабрь, 1000 нче, 2018 ел, 26 февраль, 116 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1 пунктның җиденче абзацында «(башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен түләүләрдән һәм премия түләүләреннән тыш)» сүзләрен «(авыл хуҗалыгы хезмәткәрләренә, ашыгыч һәм кичектергесез медицина ярдәме станцияләре һәм бүлекләренең күләме башкарылган эшләр сыйфаты өчен сумма чагылышыда билгеләнә торган «күчмә бригада йөртүчесе» вазыйфасы буенча эшчеләрнең гомумтармак һөнәрләренең һөнәри квалификация төркеме хезмәткәрләренә киеренке хезмәт өчен түләүләрдәнһәм премия түләүләреннән тыш)» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин